Ленар Шәех
Авылдан килгән мендәр
***Казан***
***Татарстан китап нәшрияты***
***2005***

Соңгы елларда «Сабантуй» гәзитендә эшләү дәверендә шагыйрь мәктәптә туа дигән күптәнге уема янә бер тапкыр инандым. Балачактан кочак-кочак шигырьләр ява! Тәүге кар кебек саф, ләйсән яңгырыдай сөенечле. Иң күп шигъри хисләрне Актаныш ягыннан искән ягымлы җилләр китерә. Әлфия Афзалова кебек моңлы җырчыларны, Гамил Афзал кебек халык шагыйрьләрен халкыбызга бүләк иткән як бит! Кабатланмас гүзәл табигать талантларны, бәлки, күбрәк тудырадыр.

Гамил Афзалның туган авылы Такталачыктан шигырьләрен җибәреп торган Ленар башкалардан йөз саескан арасындагы сыерчык кебек аерылып тора иде. Үзенчә сайрарга омтылуы миндә өмет уятты. Ленар чын мәгънәсендә «Сабантуй»да туды. Минзәлә педагогика көллиятен тәмамлагач, хатларда язган киңәшемне тыңлап, Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультетына укырга килде.

Әлегә мин Ленарны, үзе язганча, «бөре ачкан зирек» халәтендә күрәм. Колач җәйгән зирекләрнең матур шаулавын еракларга ишеттереп, шигъриятнең авыр юлларыннан барасы да әле барасы!

*Илдар Юзеев*

# Чаңгы, чана шуар чак

Чаңгы, чана шуар чак,
Бөтен тирә гел ап-ак.
Энҗедәй кар сипкәли,
Ал битемнән иркәли.

Җиле дә юк, тын җиһан,
Табигатьтә Кыш ич хан.
Үз сүзе сүз патшаның,
Кары калын бакчаның.

Тау өеп, чана шуып,
Бер-беребезне куып,
Мәш киләбез көн буе,
Әйтерсең лә җен туе.

«Кыш ич елга бер генә, —
Ди күрше кыз Гөлгенә. —
Җәй көне кар да булмый,
Җирдән чана да шумый».

Уйныйбыз тәмен белеп,
Ни файда өйгә кереп?
Кып-кызыл безнең йөзләр,
Сөенә, көлә күзләр.

Кыш.
Тыш.
Карлар.
Таллар
ап-ак.
Җил уйный
чак-чак.
Кар ява,
саф һава.
Төн белән
яуган кар
урамга,
юлларга
көрт яба...

Иртә
җитә.
Кояш
юаш
кына
калка,
ә ай
бата —
бозлы алка.
Кеше
эше —
кар көрәү.
Әнә берәү
селтәнә,
очып китә
көрт әнә!

Өя карлар.
Энҗе яллар
җем-җем итә
көмеш төсле
очкан чакта
төрле якка.
Акта таллар.

Кич тә
җитә.
Кояш
юаш
кына
бата,
ә ай
калка —
күккә ята.

## Шугалак

Кыш ае. Көн җепшек.
Урамда шугалак.
Кешеләр атламый,
Баралар шугалап.

Нәниләр сөенә,
Уйныйлар кар атыш.
Кар бабай ясыйлар,
Кар катыш, су катыш.

Әбиләр, бабайлар
Атлыйлар вак итеп.
Юлларга басалар
Шак итеп, сак итеп.

Апалар чырылдый,
Егыла язалар.
Бозлавык куркыныч —
Чыкмасын казалар!

Атламыйм, мин киләм
Бары тик шугалап.
Кыш ае. Көн җепшек.
Урамда шугалак.

## Каршы алыгыз

Ап-ак болытлары белән,
Җиңел толыплары белән,
Яңа солыхлары белән
Яз килә, яз килә!

Сыерчыклар шавы белән,
Кыр казлары явы белән,
Бәхет-шатлык тавы белән
Яз килә, яз килә!
Елгада боз китү белән,
Җылы көннәр җитү белән,
Карлар эреп бетү белән
Яз килә, яз килә!

Йомшак, нәфис җиле белән,
Зифа, нечкә биле белән,
Яшел чирәм җире белән
Яз килә, яз килә!

Ал-гөл чәчәккә күмелеп,
Яз килә нурга төренеп,
Каршы алыгыз йөгереп —
Яз килә, яз килә!

## Яз

Кар эри инде
Күзгә күренеп.
Пар күтәрелә
Нурга үрелеп.

Гөрләвек ага
Һәрбер урамда,
Басулар хәзер
Кара юрганда.

Сыерчык кайта,

Тургай моңлана.
Табигать-патша
Көлеп уяна.
Кояш нурлары
Битне сыпыра.
Кыш үпкәләгән —
Елап утыра.

Зәп-зәңгәр күктән
Ап-ак болытта
Язбикә килә —
Көннәр җылыта.

Кеше сәламли
Аны йөгереп,
Киң күңел белән
Назга төренеп.

Елмая, көлә
Чибәр Язбикә.
Шатлык, сөенеч
Килә бит җиргә!

## Үскәнмен

Яңгыр ява, коеп түгә
Су чиләкләп.
Рәхәтләнеп юыналар
Тал-тирәкләр.

Елмаялар, шатланалар
Кыз-чияләр:
«Тышка чыгып өз син безне,
Өз!» — дияләр.

Дәү булырга димәгәндер
Сезгә генә,
Тышка чыгам, үсәрмен, дим,
Әзгә генә.

Чәчәк кебек коенам мин
Җылы душта.

Агачлар да елмаялар
Хәзер тышта...

Яңгыр бетте, яңгыр тынды,
Лычма кием.
Ә мин һаман сикерәмен
Өскә, бииm.

Үскәнмен мин, үскәнмен мин,
Аз булса да.
Сөенәм мин, аяк астым
Саз булса да.

## Уңай сыйфатлар

Кешегә хас сыйфатлар
Сездә, зыялы затлар!
Һәммәгез тыйнак, матур,
Әхлаклы, гадел, батыр,
Тәрбияле, тәртипле,
Тәүфыйклы, юмарт, ипле;
Акыллы, тырыш, башлы,
Намуслы, кыйгач кашлы,
Тәвәккәл, кыю җанлы,
Бәхетле, шат һәм аңлы;
Ачык, юньле, гөнаһсыз,
Инсафлы, кара яксыз,
Ихтирамлы, абруйлы,
Ягымлы, чиста уйлы;
Нәзакәтле, вөҗданлы,
Эшчән, җитез һәм данлы,
Олы җанлы, йөрәкле —
Җәмгыятькә кирәкле...

Торам башымны иеп,
Шундый булсаңчы, диеп.

## Алар да үсәр әле

«Жираф» диеп үчеклиләр,

Буем озын булганга.
Мин гаепле микән инде
Шундый булып туганга?

Кайчак «колга» диләр мине,
«Чиләк» диеп атыйлар.
Берсен икенчесе белән
Кечкенәләр бутыйлар.

Берәр нәрсә кирәк булса,
«Абый!» диеп киләләр.
Минем йомшак күңелемне
Алар яхшы беләләр...

Алар да үсәрләр әле, —
Мине узып китәрләр.
Аларны да кечкенәләр
«Жираф» диеп үртәрләр.

## Мин «бишле» алгач...

Ә мин бүген «бишле» алдым,
Берне түгел, икене.
Шатлыктан да, бәхеттән дә
Минем йөрәк җилкенде.

Җиде күккә менеп киттем,
«Бишле»ләремне күргәч,
Әнием дә һуштан язды,
«Бишле» алганны белгәч.

Валидолга чапты сеңлем,
Әти идәнгә аугач.
Дәү әнием чыгып чапты,
Ике күзе акайгач.

Миңа нәрсә?.. Миңа кызык,
«Бишле»не бит мин алдым!
Өйдәгеләр, шуны күреп,
Бөтенләй телсез калды.

Аңламадым, әллә инде
«Бишле» күрмәгәннәрме?
Укытучылар артыннан
Чабып йөрмәгәннәрме?

Әллә инде укыганда
«Бишле» алмаганнармы?
Көндәлекләргә куйдырып,
Һич мактанмаганнармы?..

Аңламадым: бу зурларны
Нәрсә куркытты икән?
Әллә инде үзем куйган
Олы «бишле»ләр микән?..

## Физкультура дәресендә

Сикерәбез, йөгерәбез —
Коеп куйган көнгерә без,
Аркан буйлап үрмәлибез,
Маймыл яки шүрәле без,
Турникларда тавыклар без,
Стадионда сарыклар без,
Ә йөзгәндә балыклар без.
Үзебезне алкышларбыз —
Бассейнда аккошлар без.
Туп тибәбез, сикертәбез —
Әйтерсең лә чикерткә без,
Һәр эштә дә үз җаебыз —
Цирктагы шат аю без...

Сикерәбез, йөгерәбез —
Әйтерсең лә көнгерә без...
Кеше булмый тилмерәбез.

## Шамкай кәнфит ярата

Шамкай кәнфит ярата,
Авызга учлап ата.
Суыра да суыра,
Кәнфит гел бетеп тора.
Әни шоколад ташый,
Шамкай мизгелдә ашый.
Әтисе торт биргәли,
Сагыз белән иркәли.
Әби «Чупс» китергән,
Апа — «Крекер» чит илдән.

Туңдырма алган икән
Дәү әтисе дә иртән.
Сорый да тора кәнфит,
Үзе кычкыра: «Әз бит!»
Ул ич бердәнбер бала,
Шуңа бар тәмле аңа...
Беркөн Шамкай уфтана:
«Тешләрем сызлый, кара!
Авырта бит бик тә бик,
Кем көлә, кемгә кәмит?»
Авызы зур шар сыман,
Бер уч кәнфит бар сыман,
Күзләр исә кысылган,
Йөзе ачык кызылдан.
Корт ашый аның тешен,
Сакламаганы өчен.

## Бишек җыры

Кояш та йокларга китте
Каф таулары артына.
Аңа алмашка ай чыгар
Йолдызлар арасына.

Әлли-бәлли,
Йокла, бәби!
Әлли-бәлли,
Йокла, бәби!

Агачлар да йоклый инде,
Сыерчыклар төш күрә.
Йортларда да әкрен генә
Барча утлар да сүнә.

Әлли-бәлли,
Йокла, бәби!
Әлли-бәлли,
Йокла, бәби!

Балалар да күптән йоклый,
Юрганына күмелеп.
Нурлы ай чәчләрен тарый,
Тәрәз аша үрелеп.

Әлли-бәлли,

Йокла, бәби!
Әлли-бәлли,
Йокла, бәби!

Идәндәге нәни песи
Әнисенә сыена.
Кыйгач кашым, синең йөзең
Көмеш нурда коена.

Әлли-бәлли,
Йокла, бәби!
Әлли-бәлли,
Йокла, бәби!

Йолдызлар, нәни йолдызлар
Бары сине күзлиләр.
Эчтән генә: «Тыныч йокы,
Тәмле төшләр күр!» — диләр.

Әлли-бәлли,
Йокла, бәби!
Әлли-бәлли,
Йокла, бәби!

## Кояш баешы

Офыкка кояш тәгәри:
Бөтен җирдә яп-якты.

Күз алдымда болытларга
Эсселәнеп ут капты.

Болыт яна, болыт эри —
Мамыкларым таралды.
Кояш батты, офык кына
Бушап калды, агарды.

# Торт

Бу нинди
Тәмле торт!
Сыйфаты —
Затлы сорт!

Без аны
Пешердек.
Табадан
Тљшердек.

Матурлап
Катладык.
Ни генә
Якмадык:

Куе сљт,
Кайнатма —

**Сорамыйча капма!**

Ашарбыз
Бергәләп.
Тигезләп
Бњлгәләп...

Мактады
Һәммәсе.
«Шәп булган!»
Янәсе.

Бармаклар
Яланды.
Торт бетте,
Калмады.

Торт — исеҗ
Китмәле!

Нигәдер

Җитмәде...

## Төш

Күреп ятам татлы төш:
«Әнием пешерә төш.
Мин утырам агачта,
Алмалы алмагачта.
Авызда алма төше,
Нәни, кечедән-кече...
Уйлап торам шул килеш,
Өстән гаҗәп күренеш:
Гүзәллегенә үлеш,
Безнең тора торган төш!
Әни дәште: «Улым, төш!
Пешердем мин тәмле төш...»
Егылып киттем, бетте көч...
Уянсам, җиткән ич төш.

***

Мичтә утын шарт-шорт килә,
Чыжылдый янда таба.
Әби тәбикмәк пешерә,
Табага камыр ага.

Иң беренче пешкәнен ул
Майлап кулга тоттыра.
Балдан татлы оныкчыгын
Яратып кына тора.

***

Көзгегә карап сокланам:
Нинди чибәр икәнмен!
Әнием юкка әйтмидер:
Ал-ак тәмле шикәр мин!

***

И кәнфитне яратам соң —
Гел-гел суырып йөрим.
Мәктәптә барысы тешле,
Тешсезе — бары бер мин.

***

Әни җәен кыяр тозлый,
Тәмле кайнатма ясый.
Барыбыз да, кыш җиткәчтен,
«Җәй»не яратып ашый.

***

Яшел түбәтәен киеп,
Ул урманда утыра.
Яңгырдан соң барган кеше
Кәрзинен тиз тутыра.

## Татарлык

Бабаларым мулла булган,
Әбиләрем — абыстай.
Коръәннәре кулда булган,
Алларында алтын ай.

Әнием дә татар кызы,
Әтием — татар улы,
Шулай булгач, үземдә дә
Минем татарлык тулы.

Татарлыгым — горурлыгым,
Йолдызның иң ачыгы,
Көннең иң нурлы кояшы,
Иртәнең иң саф чыгы...

Татарлыгыңнан кимсенмә,
Бүтәннәрне кимсетмә!
Татар булып калсаң гына
Газиз милләтең бетмәс!

## Чытлы Бакый

*(Борынгылар телендә җил шулай дип аталган)*

Тәрәз шакый
Чытлы Бакый
Һәркөн кичен.
Ала үчен:
— Салкын өрәм!
Мин барыбер
Өйгә керәм!
Түбә шакый
Явыз Бакый.
Курку салып,
Уйлый сыман:
— Куркып тормам,
Атам ертып!

Тотып киртә,
Торба чиртә
Каһәр Бакый.
Өрә эчкә,
Барлык көчкә,
Шакый-шакый.

Шакып татый
Котсыз Бакый
Рәхәт хисен.
Шомландыра,
Һич йоклатмый
Мине кичен...

## Бәлеш

Мин әнигә булышам:

Күп-күп керләр юышам,
Идәнне себерешәм,
Чәй куярга керешәм.

Көндез аш пешерешәм,
Аңа токмач кисешәм.
Тузаннарны сөрткәлим,
Абыемны төрткәлим:

— Бар, әтигә булыш, — дим, —
Мал асларын кырыш, — дим. —
Мичкә дә утын кирәк,
Тыңламыйсың син бигрәк.

Абый видео карый.
Эндәшә:
— Ярый, ярый...
Чыгарга уйламый да,
Сүземне тыңламый да.

Әти кереп әйтте бер:
— Чыгып утын алып кер!
Абыем шундук торды,
Киенеп тышка шылды...

Мин бәрәңге турадым,
Ит вакларга сорадым.
Әни бәлеш ясады,
Абый керде, качмады.

Мичкә ягып җибәрде,
Битләргә җылы бәрде.
Әти тышта кайнашты,
Абый шунда адашты...

Бәлеш пешә кызарып...
...Көн буе арып-талып,
Бар эшләрне бетергәч,
Һәммәбез өйгә кергәч,

Кич белән дүртәүләшеп,
Көн турында сөйләшеп,
Өстәлгә утырыштык —

Бүген без бик тырыштык.

Мичтә бәлеш тә пешкән,
Авызда су ул истән...
Шундый тәмле бәлеше,
Бергә эшләгәч эшне.

## Безнең гаилә

Безнең гаиләбез шактый зур:
Бөтенесе биш кеше.
Өйдәге һәрбер кешенең
Бар йөкләтелгән эше.

Минем эшем — малны карау,
Сарык астын тазарту.
Апайныкы чәшке юу,
Идәннәрне агарту.

Дәү әнинең эше җайлы —
Биби, чебиләр карау.
Тишелеп, сүтелеп беткән
Оекбашларны ямау.

Әнинең шөгыле исә —
Тәмле ашлар пешерү.
Сыер савып кергәннән соң,
Безгә сөтне эчерү.

Әтинең эше — бакчада
Җиләк-җимеш үстерү.
Иртә белән мал-туарны
Көтүгә үк төшерү.

Тагын ике җан иясе
Эт белән мәче була.
Беренчесе Дускай атлы,
Икенчесе — Бикмулла.

Аларның шөгыле исә,
Тычкан тоту, йорт саклау.

Гаиләбезне караклардан,
Явыз затлардан яклау.

Менә шулай безнең өйдә —
Һәрберсенең үз эше.
Бөтенебез нидер эшли,
Юк бездә эшсез кеше.

## Каратист

Әнинең ак халаты
Миңа таман, ярады.
Буып куйдым билбавын,
Ак чалбар кидем тагын.

Билбавымда кара төс —
Мин хәзер шәп каратист.
Менә — бер!.. Менә — ике!..
Егып салдым — унике!..

Барын да сугып ектым...
Ишегалдына чыктым.
Тавыкларны куркыттым,
Этне гаҗәп утырттым.
Үрдәкләрне өркеттем,
Дөньяны дер селкеттем.

Очып чыкты ата каз,
Аяк болгыйм — аңа аз.
Мин качкач, чапты арттан,
Эләктерде балактан.
Билбавымны йолкыды,
Урамга хәтле куды.

Каз билендә кара төс —
Ай-яй оста каратист.

## Бибиләр

Сары йомшак бибиләр

Елмаеп: «Пи-пи», — диләр.
Шаяралар, уйныйлар,
Йөгереп һич туймыйлар.

Хәтфә үлән йолкыйлар,
Аргач, бергә йоклыйлар.
Суда да коеналар,
Туйганчы юыналар.

Ә мин аларны карыйм,
Һәр минут саен барлыйм...
Ала карга: «Кар-р, кар-р, — ди. —
Миңа азык бар, бар, — ди.

Пумалам белән аны
Куам. Беләм карганы!
Урлашыр иде бугай,
Тиз ташыр иде бугай!

Мин аңа бирәмме соң?!
Ташлыйм да керәмме соң?!
Селәүчән тотсын әнә,
Чебеннәр йотсын әнә!..

## Алты яшьлек көтүче

Җәй көнендә берьялгызым
Көтү көткән бар ла ул.
Кич белән сыер кайтканда,
Шаулады бөтен авыл.

Кемнең үгезе кайтмаган,
Берәүләрнең — танасы.
Кайтмый калган таналарны
Кайдан эзләп табасы?

Кемнеке иртән үк кайткан,
Берәүнеке — көндезен.
Кайберәүләр эзләгәннәр
Сыерларын төнозын...

Их, дусларым, әйтсәм әйтим,
Уйлап карагыз менә:

Миңа бит әле нибары
Тулы алты яшь кенә.

Буем да кечкенә генә,
Аякларым да кыска.
Төнлә белән куркамын мин
Чыгарга ялгыз тышка...

...Миндәй нәни көтүчеләр
Тарихта булмагандыр.
Бәлкем, әле сыерлары
Хуҗасын юллагандыр.

## Сәет бабай

Сәет бабай сиксәндә,
Ярый алтмыш бирсәң дә;
Егетләр кебек, кара,
Әнә урамнан бара!

Гәүдәләр төз, чәчләр чал,
Йөзе ачык, теле — бал.
Шаяртырга ярата,
Елмаюын тарата.

Сакал, мыек кырылган,
Авыз, ирен ерылган.
Ә күзләрдә ут уйный,
Бабай нәрсәләр уйлый?..

Сәет бабай сиксәндә,
Ярый илле бирсәң дә;
Малайлар кебек йөри,
Урамда ул кар көри.

Изү ачык, күңел шат,
Бабайга син күзең ат:
Ике генә селтәнә,
Очып китә көрт әнә!

Ишегалды чистара,
Комы да чыгып кала.
Нинди дәртле бабай бу?
Әллә эшчән малаймы?..

Сәет бабай сиксәндә,
Ярый кырык бирсәң дә;
Көне гел кызган таба!
Ә бабай печән чаба.

Бер кибәне уң якта,
Икенчесе — сул якта,
Өченчесе — чүмәлә.
Аның эшен күргәлә!

Кайчан гына карама,
Кайчан гына урама,
Сәет бабай иелгән —
Ул бит эшләп сөенгән.

Йә бакчада чүп утый,
Ансы да утыз сутый.
Йә урманда утында,
Һич ала алмый тын да.

Беркөн умарта карый,
Аннан бал белән сыйлый.
Сәет бабай ничәдә?
Була егет дисәң дә...

## «Батырлык»

Әй бу шаян черкиләр!
Төн дә мине үртиләр.
«Без килдек... Без-з-з... без-з-з...» диләр,
Туктаусыз безелдиләр.

Биткә килеп куналар.
Каян күрә соң алар?..
...Камалышта каламмы? —
Югыйсә кап-караңгы.

Әй бу шаян черкиләр!
Йоклатмыйлар, үртиләр.
Киләләр дә тешлиләр,
Кусаң да син, кумасаң да,
Үз эшләрен эшлиләр.

Чак кына уйлап яттым,

Ахры, әмәлен таптым! —
Яшерен көрәш ачтым —
Юрган астына качтым.

## Җәй үтеп бара сыман...

Кояш та иренеп карый
Болытлар арасыннан.
Ак толыпларга ияреп,
Җәй үтеп бара сыман.

Каен сары яфракларын
Бирә җилләр иркенә.
Җәйге көннәр, җәйге көннәр
Яфрак булып җилпенә.

Каз-үрдәк тә, моңаешып,
Канатын кага сыман.
Аларның күз яше булып,
Күктән моң ага сыман.

Адашып китәрсең кебек
Төннәрнең карасыннан.
Төнге суыкка ияреп,
Җәй үтеп бара сыман.

## Яхшы гамәл

Айсылуның чәчен тарттым
юри генә,
Шуңа микән, эндәшмичә
йөри менә.

Белми микән минем аны
яратканны,
Чәчен тартып, сөюемне
аңлатканны?..

...Бүгеннән үк яхшы гамәл
отып кайтам —
Дәресләрдән соң букчасын

тотып кайтам.

## Бакчадагы алмагач

Бакчадагы алмагач
Үсеп килә
Карагач,
Чәчәккә бөреләнеп,
Елдан-ел төрлеләнеп.

Кышкы салкынга түзеп,
Җәйге челләгә түзеп,
Чөнки карыймын үзем.
Бөреләр чәчәк булгач,
Чәчәктән алма тугач,
Җыяр идем чиләккә,
Җыяр идем иләккә,
Бирер идем әнигә,
Бирер идем әбигә.
Бирер идем әтигә,
Урамдагы бәтигә.
Бирер идем бабайга,
Оядагы Акбайга.

Урамны буйлар идем —
Барысын сыйлар идем,
Алмагачка рәхмәт әйтеп,
Кочаклап сөяр идем.

## Таш атучы Рузалин

Бөтен кеше шакката:
Рузалин гел таш ата.

Таш ата ул казга да,
Лилия, Гөлназга да...

«Мин, — ди, — кояшны күктән
Бәреп төшерәм, җиткән!..»

Шунда ул көчкә-көчкә,
Бер ташны чөйде өскә...

Сүз әйтеп булмый ташка —
Килде дә төште башка...

## Әнисенең киңәше

«Инде үсеп җиткәнсең,
Бишне узып киткәнсең.
Әйдә, кызым, Алинә,
Кулларыңа ал инә.

Аңа җебен саплап куй,
Төйнә, ике катлап куй.
Читкә куй уеныңны,
Ямале оегыңны.

Тек вак итеп атлатып,
Торыр һәркем шаккатып...

Ал да җепнең озынын...
Үскәч син үз кызыңны
Өйрәтерсең тегәргә,
Ямарга һәм чигәргә».

Уңган кыз ул Алинә,
Тегүче булыр менә.
Тегәр вак-вак атлатып,
Торыр һәркем шаккатып.

## Авылдан килгән мендәр

Авылдан мендәр килгән.
Адресны каян белгән?..

Үзе йомшак, җылы, киң,
Әни кочагына тиң...

Рәхәт анда ятуы,
Мендәр назын татуы...

...Җәй, авыл хәтеремдә.

Мин, дәү әни, энем дә
Бәбкә саkладык бергә...

Җәем сыенган мендәр,
Тутырган аны кемнәр?..

...Мендәремнең эчендә
Иртәсен дә, кичен дә
Бәбкәләр пипелдиләр:
«Ник сакламадың», — диләр.

## Мин кем малае?

Мин — әниемнең малае,
Юаш та, оялчан да.
Кеше хәленә керүчән,
Беркатлы, оялчан да.

Мин — әтиемнең малае,
Ике кулыма һөнәр —
Балтасы да, пычкысы да,
Өтергесе дә күнәр.

Мин — дәү әнием малае,
Ипи дә баса беләм...
Ачкыч табып, кешеләрнең
Күңелен ача беләм.

Мин — дәү әтием малае,
Тырыш, әзрәк тыйнак та.
Сүзләрем сибелеп ятмый,
Әз-мәз үҗәт, җыйнак та...

Шуңа күрә миндә яши
Әтием һәм әнием,
Чак кына дәү әтием һәм
Әз-мәз генә әбием.

## Очкылык

Килеп капты очкылык,

Булмый гына ычкынып.

«Ык!» итәм дә «ык!» итәм,
Үзем авызга төртәм:

— Бар инде, бар, «ык!» — димен, —
Авызымнан чык! — димен...

Булмый берни эш кылып,
Китми генә очкылык...

Дәү әни: «Тиз су эч, — ди, —
Керер җиңәрлек көч...» — ди.

...Китте-барды ычкынып,
Бар иде, юк очкылык...

## Күләгәле бүлмәдә

Нәни генә бүлмәгә
Кояш төшми, күләгә.

Утыра бер кыз бала,
Тәрәзгә карап ала.

Апасы, һай, кызгана,
Бик ямансу кызга да.

Күзләрдән уй ташыган,
Хыял иле ачылган.

Үткәннәр уйландыра,
Уй йокыга талдыра.

Кайчандыр бу бүлмәгә
Һич кермәде күләгә.

Бар җирдә шау-шу иде,
Гел язгы ташу инде.

Елмаеш, көлеш иде,
Шаярып үлеш иде...

...Бүлмәне тынлык алган.
Мәктәптә мөгаллим белән

Бер бөртек бала калган.

## Минем әни

*(Анжела Зоммер-Боденбург буенча)*

Минем әни чын тылсымчы —
Уйларны укый ала.
Минем холкымны да белә —
Магия ич бу, кара!

Әнинең кочагы җылы,
Мин китәм анда эреп.
Мин бәхетле, миңа рәхәт
Гүя күктәге кебек.

## Яңгыр ява

*(Роза Пфлунг буенча)*

Яңгыр ява, яңгыр ява,
Яфрактан тамчы тама.
Бу искиткеч зур тылсымдыр,
Үләннәрдән су ага.

Өебездән чыгабыз да,
Без туйганчы чабабыз.
Яңгырдан бетмәс рәхәтлек,
Сихри ләззәт алабыз.

Безнең эшне куәтләпме,
Сайрый биектә тургай.
Тик өстебез манма булган,
Бер коры җир юк бугай.

## Курчакка бишек җыры

*(Клаус В. Хоффман буенча)*

Йокла, йокла, курчагым,
Тышта йөри әллә кем.
Җил иркәли агачларны,
Пышылдый: «Хәерле төн!»

# Ил гизүченең төнге җыры

*(И. В. Гёте буенча)*

Тау өсләре йоклый сыман
Төнге караңгылыкта;
Үзәннәр дә күмелгәннәр
Тылсымлы бер тынлыкка.

Агачларның очларында
Сизелми җил сулышы;
Кошлар да тынып калганнар —
Ерак кояш чыгышы.

Юлда да тузан күренми,
Селкенми һичбер яфрак.
Чак кына көт, озакламый
Ял алырсың син азрак.

# Кристинаның сәгате

*(Клаус В. Хоффман буенча)*

Кристинаның сәгате бар
Төрле төскә буялган.
Кәҗә кебек «мә»елди ул,
Эт булып өрә алдан.

Иртән җырлый ул һәм көлә,
Мотордай гырлый, хактан!
Кристина уянмый, тормый —
Сәгать тарта колактан.

Ләкин болары да бушка,
Сәгать әйтә: «Мин чүгәм!»
Кызны, сыйпап кулы белән,
Алсу битеннән үбә.

# Ябалак

*(Иозеф Гуггенмос буенча)*

Караңгы төн. Сакта тора
Ябалак.
Зур күзләре белән нидер
Чамалап.
Һәрбер адымны ишетә
Дөм төнлә,
Мин күрмәгән нәрсәне дә
Ул күрә.

## Табышмак

*(Герман Арнхольдка ияреп)*

Бу бик кыен табышмак!
Аңламагач, табыш вак:
Ат ул дүрт мөгезлеме?..
Куян алты күзлеме?..
Ишәк селәү ашыймы?..
Төлке башын кашыймы?..
Эт тәмәке тартамы?..
Тычкан мәче тотамы?..
Алар сайрый?.. Өрәме?..
Оныттым, көлмә әле!..
Үземә сорау бирәм:
Тагын нәрсәләр беләм?..
Кәҗә сәламләшәме?..
Тавык хәрәмләшәме?..
Нәни дуңгыз «ыс»лыймы?..
Кәккүк өйдә кышлыймы?..
Күгәрченнәр җырлыймы?..
Күркәләр дә мырлыймы?..
Сарык, ялгыз йоклаганда,
Кеше кебек гырлыймы?..

Уйлап карагыз сез дә:
Дөреслек бармы сүздә?..

## Күлдә

*(Билгесез авторныкы)*

Күлдәге су җып-җылы.
Бүген безнең күңел шат,
Су керергә барабыз —
Иярсәң, син, безне тап...

...Бер, ике, өч, —
Чалбарны,
Майка, итекне салдык.
Чип-чиста суга «чупылт!..» —
Бакалар булып калдык.

Җәйнең кызу кояшы
Күктән ярга, шат карап,
Бөтен тәнне каралта,
Әйтерсең без — шоколад.

## Ялгыз чыршы

*(Генрих Гейне буенча)*

Себердәге шәрә биеклектә
Ялгыз чыршы күккә үрелгән.
Изрәп ята ап-ак тун эчендә,
Карга, бозга агач төренгән.

Ул төшендә пальма дустын күрә,
Ә иптәше таңнар илендә.
Чыршы ялгыз, сүзсез сагышлана,
Җылы биргән кыя билендә.

## Һәр һөнәргә...

*(Алманчадан)*

Яшел, яшел, яшел төстә
Кигән чалбар, кепка, күлмәк.
Яшел генә минем өстә —
Сизгер аучымын мин, димәк.

Ап-ак, ап-ак, ап-ак төстә
Кигән чалбар, кепка, күлмәк.
Ап-ак кына минем өстә —

Тегермәнчемен мин, димәк.

Зәңгәр, зәңгәр, зәңгәр төстә
Кигән чалбар, кепка, күлмәк.
Зәңгәр генә минем өстә —
Шәп буяучымын мин, димәк.

Чуар, чуар, чуар төстә
Кигән чалбар, кепка, күлмәк.
Чуар гына минем өстә —
Шаян рәссаммын мин, димәк.

Кара, кара, кара төстә
Кигән чалбар, кепка, күлмәк.
Кара гына минем өстә —
Корыч коючы мин, димәк.

Һәр һөнәргә төрле-төрле
Кепка, күлмәк, чалбар кирәк.
Борын-борын заманда,
Әле син булмаганда,
Әле мин тумаганда,
Яшәгәннәр куяннар,
Буйволлар һәм боланнар;
Ябалак, сыерчыклар,
Каргалар һәм чыпчыклар.
Куяннарның колагы
Нигәдер кыска булган.
Сез тыңлагыз, ә мин башлыйм
Әкиятемне шуннан.

Көннәр арты көннәр үткән,
Ямьле җәй килеп җиткән;
Бар табигать җанланган,
Яшәргән һәм яңарган.
Болыннар да күмелгәннәр
Төрле-төрле гөлләргә,
Сары һәм ак төнбоеклар
Калыкканнар күлләрдә.
Күбәләкләр очып йөргән,
Көн яктысында көлеп.
Нурлы кояш җиләкләрне
Киткән кызылга төреп.
Үлән үскән, печән үскән

Буйволларга, куянга,
Кәҗәләргә, боланга,
Сарыкка һәм йомранга.

Нәни куян шул болында
Чәчәкләр җыеп йөргән,
Яшел әрекмән татыгач,
Гөлле такыя үргән.
Кызыл җиләк ашый-ашый,
Татлы йокыга талган.
Тәмле төшләр күргән куян.
(Төшләре нинди — балдан!)
Аны-моны уйламыйча,
Буйвол үлән ашаган,
Шунда, үзе дә сизмәстән,
Куянның нәни колагын
Кабып чәйни башлаган.
Кыяк диеп белгән ич ул
Соры кыска колакны,
Ә куянның коты очкан,
Күреп «мөгезле ат»ны,
«Инде беттем, эләктем» дип,
Уйлаган эчтән генә,
Иң соңгы көчтән генә.
Кычкырып та караган ул,
Селкенеп тә караган.
Куян шулай чайпалганда,
Колагы да сузылган.
Элеккесеннән исә ул
Биш мәртәбә зур булган.
Чәйнәп тә тәмен тапмагач,
Буйвол: «Тфү, тфү, тфү, — дигән, —
Мондый куак бу тирәгә
Кайсы җил белән килгән?..»
Алдын-артын карамыйча,
Куян чапкан урманга.
Хәзер колак кыска түгел,
Ә искиткеч зур анда...

Шушы көннән куяннар
Озынколак булганнар.

# Эчтәлек

*Илдар Юзеев.* «Соңгы елларда...» ...............
Авылдан килгән мендәр ...................
Чаңгы, чана шуар чак ......................
Кыш ...............................
Кышкы таң ...........................
Шугалак ............................
Яз җиңә .............................
Каршы алыгыз ..........................
Яз ................................
Үскәнмен ............................
Кем буяу түккән? .........................
Уңай сыйфатлар .........................
Алар да үсәр әле .........................
Мин «бишле» алгач... ......................
Физкультура дәресендә ....................
Башым катты ..........................
Шамкай кәнфит ярата ......................
Бишек җыры ...........................
Бала йоклый ...........................
Кояш баешы ...........................
Торт ...............................
Төш ...............................
«Мичтә утын шарт-шорт килә...» ...............
«Көзгегә карап сокланам...» .................
«И кәнфитне яратам соң...» ..................
«Әни җәен кыяр тозлый...» ..................
«Яшел түбәтәен киеп...» ....................
Татарлык ............................
Чытлы Бакый ..........................
Бәлеш ..............................
Безнең гаилә ..........................
Каратист ............................
Бибиләр .............................
Алты яшьлек көтүче ......................
Сәет бабай ............................
«Батырлык» ..........................
Җәй үтеп бара сыман... ....................
Яхшы гамәл ..........................
Бакчадагы алмагач .......................
Таш атучы Рузалин .......................
Әнисенең киңәше ........................
Авылдан килгән мендәр ....................
Мин кем малае? .........................
Очкылык ............................
Күләгәле бүлмәдә .......................

**Алманчадан тәрҗемәләр**

Минем әни ...........................
Яңгыр ява ............................
Курчакка бишек җыры ....................
Ил гизүченең төнге җыры ...................
Кристинаның сәгате ......................
Ябалак .............................
Табышмак ...........................
Күлдә ..............................
Ялгыз чыршы .........................
Һәр һөнәргә ...........................
Ни өчен куянның колагы озын? *(Әкият)* ..........

УДК 820/89 (470)
ББК 84(2Рос=Тат)–5
Ш 91

Рәссамы ***Алла Айсина***

Авылдан килгән мендәр: Шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 71 бит.
ISBN 5–298–04122–1
© Татарстан китап нәшрияты, 2005

Издание для детей и юношества

*Ленар Шаех*
*(Шаехов Ленар Миннемохимович)*

**ПОДУШКА ИЗ ДЕРЕВНИ**

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәсметдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректор *Г.Х.Сундукова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 16.06.2005. Форматы 70x100 1/16.
Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 5,85.
Шартлы буяу-оттиск 24,70. Нәшер-хисап табагы 3,38. Тиражы 5000 д. Заказ А-448.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/
E-mail: tki@books.kazan.ru

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.